ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 116-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кертелгән «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 116-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2025 елның 14 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2025 елның 26 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 426-VII ДС

Проект

Закон чыгару инициативасы
хокукы субъекты –
Татарстан Республикасы Рәисе

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында

### 1 статья

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба шулай ук – Фонд) бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 100 073 046,3 мең сум, шул исәптән Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 87 013 891,9 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 11 873 469,7 мең сум итеп;

2) Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 100 073 046,3 мең сум итеп.

2. 2027 һәм 2028 еллар план чорына Фонд бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2027 елга Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 107 022 623,4 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 12 792 816,0 мең сум һәм 2028 елга 111 815 337,9 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 13 782 241,1 мең сум итеп;

2) 2027 елга Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 107 022 623,4 мең сум һәм 2028 елга 111 815 337,9 мең сум итеп.

### 2 статья

Фонд бюджетына керемнәр керүне түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2026 елга әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

2) 2027 һәм 2028 еллар план чорына әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә.

### 3 статья

Фонд бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне түбәндәгечә расларга:

1) 2026 елга әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә;
2) 2027 һәм 2028 еллар план чорына әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә.

**4 статья**

2026 елда Фонд бюджетын үтәгәндә әлеге Закон белән расланган күләмнәрдән тыш фактта алынган һәм максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар, әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә, Фонд бюджетының җыелма бюджет язуына үзгәрешләр кертеп, бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры китереп, Фонд бюджеты чыгымнарын арттыруга җибәрелә дип билгеләргә.

**5 статья**

Фондның вакытлыча тотылмый торган акчаларын урнаштырудан алынган процент кереме күләмендәге акчалар Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруга җибәрелә дип билгеләргә.

**6 статья**

1. 2026 елга Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары күләмен 5 745 139,8 мең сум, 2027 елга 6 135 466,4 мең сум, 2028 елга 6 470 184,6 мең сум итеп билгеләргә.

2. Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары 2026 елда түбәндәгеләргә җибәрелә дип билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруны медицина ярдәменә түләү өчен җитешми торган акчаларны «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 6 өлеше нигезендә иминләштерүче медицина оешмасына бирү юлы белән өстәмә финанс белән тәэмин итүгә;

2) иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түбәндәгеләр өлешендә исәп-хисаплар ясауга:

3) квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә;

4) медицина оешмаларының табибларга һәм урта медицина персоналына хезмәт өчен түләүгә тотыла торган чыгымнарын финанслашуга;

5) гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яисә) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу янаганда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы белән билгеләнгән медицина ярдәме күләмнәре кимелүгә бәйле рәвештә медицина оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрен компенсацияләү чараларын финанс белән тәэмин итүгә.

**7 статья**

Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруда катнаша торган иминләштерүче медицина оешмалары өчен мәҗбүри медицина иминияте буенча эш алып баруга чыгымнар нормативын 2025 елда мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итүнең җан башына дифференциациялəп исәпләнгән нормативлары буенча иминләштерүче медицина оешмасына кергән акчалар суммасыннан 0,85 процент күләмендә һәм 2025 елның декабрендә мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итүнең җан башына дифференциациялəп исәпләнгән нормативлары буенча иминләштерүче медицина оешмасына 2026 елда кергән акчалар суммасыннан 0,81748 процент күләмендә билгеләргә.

**8 статья**

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы $3^1$ пункт нигезендә 2026 елда Фонд бюджетының җыелма бюджет исемлегенә әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә үзгәрешләр кертү өчен өстәмә нигезләр булып түбәндәгеләр тора дип билгеләргә:

1) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибенә үзгәрешләр кертү;

2) 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы $3^2$ пунктның өченче – алтынчы абзацларында каралган нигезләр буенча үзгәрешләр кертү;

3) 2026 елга бюджет ассигнованиеләрен әлеге Законда «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлеге, «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе, «Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү» максатчан статьясы буенча каралган бюджетлар чыгымнары классификациясе чыгымнары төрләре арасында 2026 елда чыгымнарның күрсәтелгән бүлеге, бүлекчәсе һәм максатчан статьясы буенча бюджет ассигнованиеләрен файдаланганда экономияләү хисабына яңадан бүлү;

4) 2026 елда Фонд бюджетына әлеге Закон белән расланган 2026 елга бюджет ассигнованиеләре күләмнәреннән тыш медицина хезмәткәрләренә квалификация күтәрү программалары буенча өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә җибәрелергә тиешле акчалар керү.

**9 статья**

Фонд бюджетының агымдагы финанс елы башына файдаланылмый калган, бюджет турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш булмаган акчалары, әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә, Фонд бюджетының җыелма бюджет язуына тиешенчә үзгәрешләр кертеп, Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары исәбеннән, агымдагы финанс елында Татарстан Республикасында Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы үтәлешен, иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты

территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәменә түләүне, квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын, финанс белән тәэмин итүгә җибәрелә дип билгеләргә.

**10 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына
Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри
медицина иминияте фонды бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

**2026 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре**

(мең сумнарда)

| Бюджет классификациясе кодлары | Керем исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 395 2 00 00000 00 0000 000 | Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 100 073 046,3 |
| 395 2 02 00000 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетла-рыннан алынган кире кайтарылмый торган кертемнәр | 100 073 046,3 |
| 395 2 02 50000 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 88 199 576,6 |
| 395 2 02 55093 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри меди-цина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонд-лары бюджетларына субвенцияләр | 87 013 891,9 |
| 395 2 02 59999 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 185 684,7 |
| 395 2 02 59999 09 0000 150 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 185 684,7 |
| 395 2 02 90000 00 0000 150 | Бюджет системасының башка бюд-жетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган бүтән кертемнәр | 11 873 469,7 |
| 395 2 02 90020 00 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 11 873 469,7 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 02 90029 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 11 873 469,7 |
| | Керемнәр, барлыгы | 100 073 046,3 |

«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына
Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри
медицина иминияте фонды бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

**2027 -2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре**

(мең сумнарда)

| Бюджет классификациясе кодлары | Керем исеме | План чоры | |
|---|---|---|---|
| | | 2027 ел | 2028 ел |
| 395 2 00 00000 00 0000 000 | Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 107 022 623,4 | 111 815 337,9 |
| 395 2 02 00000 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан алынган кире кайтарылмый торган кертемнәр | 107 022 623,4 | 111 815 337,9 |
| 395 2 02 50000 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 94 229 807,4 | 98 033 096,8 |
| 395 2 02 55093 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр | 92 964 681,8 | 96 683 207,8 |
| 395 2 02 59999 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 265 125,6 | 1 349 889,0 |
| 395 2 02 59999 09 0000 150 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 265 125,6 | 1 349 889,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 395 2 02 90000 00 0000 150 | Бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган бүтән кертемнәр | 12 792 816,0 | 13 782 241,1 |
| 395 2 02 90020 00 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 12 792 816,0 | 13 782 241,1 |
| 395 2 02 90029 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 12 792 816,0 | 13 782 241,1 |
| | Керемнәр, барлыгы | 107 022 623,4 | 111 815 337,9 |

«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта

**2026 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү**

(мең сумнарда)

| Исеме | Бюджет классификациясе кодлары | | | | | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мин | Рз | ПР | ЦСР | ВР | |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 00 | | | 464 529,2 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 13 | | | 464 529,2 |
| Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләре | 395 | 01 | 13 | 73 0 00 0000 0 | | 464 529,2 |
| Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары аппаратлары тарафыннан функцияләр башкару | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 0000 0 | | 464 529,2 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 0 | | 464 529,2 |
| Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды аппараты тарафыннан функцияләр башкаруга чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | | 464 529,2 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| финанс белән тәэмин итү | | | | | | |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләүләргә чыгымнар | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 100 | 352 468,9 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 200 | 107 546,8 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 300 | 100,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 800 | 4 413,5 |
| Сәламәтлек саклау | 395 | 09 | 00 | | | 99 431 042,0 |
| Ашыгыч медицина ярдәме | 395 | 09 | 04 | | | 11 175,4 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 04 | 01 0 00 0000 0 | | 11 175,4 |
| Федераль (региональ) проектлар | 395 | 09 | 04 | 01 2 00 0000 0 | | 4 856,4 |
| «Башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» федераль проекты | 395 | 09 | 04 | 01 2 Д6 0000 0 | | 4 856,4 |
| Медицина ярдәме күрсәтү максатларында авиация хезмәтләре сатып алуны тәэмин итүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 04 | 01 2 Д6 5554 0 | | 4 856,4 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 2 Д6 5554 0 | 300 | 4 856,4 |
| Процесс чаралары комплекслары | 395 | 09 | 04 | 01 4 00 0000 0 | | 6 319,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесс чаралары комплексы | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0000 0 | | 6 319,0 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 0 | | 6 319,0 |
| Махсуслаштырылган медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 3 | | 6 319,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 3 | 300 | 6 319,0 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 395 | 09 | 09 | | | 99 419 866,6 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 09 | 01 0 00 0000 0 | | 99 419 866,6 |
| Процесс чаралары комплекслары | 395 | 09 | 09 | 01 4 00 0000 0 | | 99 419 866,6 |
| «Югары технологияле медицина ярдәме һәм профилактика, диагностика, дәвалау һәм реабилитация ысулларын клиник апробацияләү кысаларында күрсәтелә торган медицина ярдәме» процесс чаралары комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 0000 0 | | 3 220 551,9 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 R402 0 | | 3 220 551,9 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 R402 0 | 300 | 3 220 551,9 |
| «Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү» процесс чаралары комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0000 0 | | 700 620,3 |
| Паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән балаларга да, чыгымнар | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0202 0 | | 700 620,3 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0202 0 | 300 | 700 620,3 |
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесс чаралары комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0000 0 | | 95 498 694,4 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша башлыча бер-каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 0 | | 7 763 647,0 |
| Махсуслаштырылган медици-на ярдәме, ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуа-циясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша башлыча берканаллы финанс-лауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 3 | | 7 763 647,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 3 | 300 | 7 763 647,0 |
| Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0539 0 | | 1 185 684,7 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәме | | | | | | |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0539 0 | 300 | 1 185 684,7 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 0 | | 86 549 362,7 |
| Татарстан Республикасында медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 1 | | 84 551 958,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 1 | 300 | 84 551 958,0 |
| Татарстан Республикасында иминләштерелгән һәм медицина ярдәмен иминләштерү территориясеннән читтә алган затларга медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 2 | | 1 997 404,7 |
| Бюджетара трансфертлар | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 2 | 500 | 1 997 404,7 |
| Социаль сәясәт | 395 | 10 | 00 | | | 177 475,1 |
| Халыкны социаль тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | | | 177 475,1 |
| «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы | 395 | 10 | 03 | 03 0 00 0000 0 | | 177 475,1 |
| Процесс чаралары комплекслары | 395 | 10 | 03 | 03 4 00 0000 0 | | 177 475,1 |
| «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү» процесс чаралары комплексы | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0000 0 | | 177 475,1 |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0521 0 | | 170 074,2 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль тээмин итү һəм халыкка бүтəн түлəүлəр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0521 0 | 300 | 170 074,2 |
| Тыл хезмəтчəннəренə социаль ярдəм чараларын тээмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0522 0 | | 341,5 |
| Социаль тээмин итү һəм халыкка бүтəн түлəүлəр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0522 0 | 300 | 341,5 |
| Хезмəт ветераннарына соци-аль ярдəм чараларын тээмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0531 0 | | 762,6 |
| Социаль тээмин итү һəм халыкка бүтəн түлəүлəр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0531 0 | 300 | 762,6 |
| Социаль ярдəмнең башка төрлəрен күрсəтү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0551 0 | | 6 296,8 |
| Социаль тээмин итү һəм халыкка бүтəн түлəүлəр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0551 0 | 300 | 6 296,8 |
| Чыгымнар, барлыгы | 395 | | | | | 100 073 046,3 |

«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына 4 нче кушымта

**2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү**

(мең сумнарда)

| Исеме | Бюджет классификациясе кодлары | | | | | План чоры | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мин | Рз | ПР | ЦСР | ВР | 2027 ел | 2028 ел |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 00 | | | 463 610,9 | 503 796,3 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 13 | | | 463 610,9 | 503 796,3 |
| Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары идарә органнары эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләре | 395 | 01 | 13 | 73 0 00 0000 0 | | 463 610,9 | 503 796,3 |
| Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары аппаратлары тарафыннан функцияләр башкару | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 0000 0 | | 463 610,9 | 503 796,3 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 0 | | 463 610,9 | 503 796,3 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| финанс белән тәэмин итү | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды аппараты тарафыннан функцияләр башкаруга чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | | 463 610,9 | 503 796,3 |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләүләргә чыгымнар | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 100 | 386 859,6 | 425 234,8 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 200 | 72 065,4 | 73 696,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 300 | 100,0 | 100,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 800 | 4 585,9 | 4 765,4 |
| Сәламәтлек саклау | 395 | 09 | 00 | | | 106 374 438,4 | 111 121 127,5 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ашыгыч медицина ярдәме | 395 | 09 | 04 | | | 11 175,4 | 11 175,4 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 04 | 01 0 00 0000 0 | | 11 175,4 | 11 175,4 |
| Федераль (региональ) проектлар | 395 | 09 | 04 | 01 2 00 0000 0 | | 4 856,4 | 4 856,4 |
| «Башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» региональ проекты | 395 | 09 | 04 | 01 2 Д6 0000 0 | | 4 856,4 | 4 856,4 |
| Медицина ярдәме күрсәтү максатларында авиация эшләре сатып алуны тәэмин итүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 04 | 01 2 Д6 5554 0 | | 4 856,4 | 4 856,4 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 2 Д6 5554 0 | 300 | 4 856,4 | 4 856,4 |
| Процесс чаралары комплекслары | 395 | 09 | 04 | 01 4 00 0000 0 | | 6 319,0 | 6 319,0 |
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесс чаралары комплексы | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0000 0 | | 6 319,0 | 6 319,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша башлыча берканаллы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 0 | | 6 319,0 | 6 319,0 |
| Махсуслаштырылган медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша башлыча берканаллы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 3 | | 6 319,0 | 6 319,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 3 | 300 | 6 319,0 | 6 319,0 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 395 | 09 | 09 | | | 106 363 263,0 | 111 109 952,1 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 09 | 01 0 00 0000 0 | | 106 363 263,0 | 111 109 952,1 |
| Процесс чаралары комплекслары | 395 | 09 | 09 | 01 4 00 0000 0 | | 106 363 263,0 | 111 109 952,1 |
| «Югары технологияле медицина ярдәме һәм профилактика, | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 0000 0 | | 3 420 277,1 | 3 631 926,5 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| диагностика, дәвалау һәм реабилитация ысулларын клиник апробацияләү кысаларында күрсәтелә торган медицина ярдәме» процесс чаралары комплексы | | | | | | | |
| Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 R402 0 | | 3 420 277,1 | 3 631 926,5 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 R402 0 | 300 | 3 420 277,1 | 3 631 926,5 |
| «Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү» процесс чаралары комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0000 0 | | 759 472,7 | 821 326,2 |
| Паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән балаларга да, чыгымнар | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0202 0 | | 759 472,7 | 821 326,2 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0202 0 | 300 | 759 472,7 | 821 326,2 |
| «Татарстан Республикасы | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0000 0 | | 102 183 513,2 | 106 656 699,4 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесс чаралары комплексы | | | | | | | |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша башлыча берканаллы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 0 | | 8 417 316,7 | 9 127 398,9 |
| Махсуслаштырылган медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша башлыча берканаллы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 3 | | 8 417 316,7 | 9 127 398,9 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 3 | 300 | 8 417 316,7 | 9 127 398,9 |
| Россия Федерациясенең башка субъектлары | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0539 0 | | 1 265 125,6 | 1 349 889,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәме | | | | | | | |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0539 0 | 300 | 1 265 125,6 | 1 349 889,0 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 0 | | 92 501 070,9 | 96 179 411,5 |
| Татарстан Республикасында медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 1 | | 90 369 840,0 | 93 905 388,2 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 1 | 300 | 90 369 840,0 | 93 905 388,2 |
| Татарстан Республикасында иминләштерелгән һәм медицина ярдәмен иминләштерү территориясеннән читтә алган затларга | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 2 | | 2 131 230,9 | 2 274 023,3 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | | | | | | | |
| Бюджетара трансфертлар | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 2 | 500 | 2 131 230,9 | 2 274 023,3 |
| Социаль сәясәт | 395 | 10 | 00 | | | 184 574,1 | 190 414,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | | | 184 574,1 | 190 414,1 |
| «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы | 395 | 10 | 03 | 03 0 00 0000 0 | | 184 574,1 | 190 414,1 |
| Процесс чаралары комплекслары | 395 | 10 | 03 | 03 4 00 0000 0 | | 184 574,1 | 190 414,1 |
| «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү» процесс чаралары комплексы | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0000 0 | | 184 574,1 | 190 414,1 |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0521 0 | | 176 877,2 | 182 473,7 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0521 0 | 300 | 176 877,2 | 182 473,7 |
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0522 0 | | 355,1 | 366,3 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0522 0 | 300 | 355,1 | 366,3 |
| Реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0531 0 | | 793,1 | 818,2 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0531 0 | 300 | 793,1 | 818,2 |
| Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0551 0 | | 6 548,7 | 6 755,9 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0551 0 | 300 | 6 548,7 | 6 755,9 |
| Чыгымнар, барлыгы | 395 | | | | | 107 022 623,4 | 111 815 337,9 |

**«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА ЯЗУЫ**

«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын (алга таба – закон проекты) формалаштыру бюджет турындагы законнар, «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль закон һәм «Эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертеме тарифы күләме һәм аны хисаплап чыгару тәртибе турында» Федераль закон таләпләре нигезендә гамәлгә ашырылды.

Чираттагы финанс елына, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба - Фонд) бюджетының төп характеристикалары 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Россия Федерациясен һәм Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фараз күрсәткечләре нигезендә төзелде.

Фонд бюджеты күрсәткечләрен хисаплап чыгару 2025 елның 1 гыйнвары хәленә карата мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән 3 827,6 мең кеше, шул исәптән эшләмәүче 1 962,1 мең кеше санынннан чыгып гамәлгә ашырылды.

Фонд бюджеты керемнәренең гомуми күләме түбәндәгечә планлаштырыла:

100 073,0 млн. сум – 2026 елга;

107 022,6 млн. сум – 2027 елга;

111 815,3 млн.сум – 2028 елга.

Фонд бюджеты керемнәре өлешенең төп чыганаклары булып Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды субвенцияләре, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Россия Федерациясе субъектларының территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан керә торган бюджетара трансфертлар тора.

2026 елда планлаштырыла торган керемнәрнең шактый өлеше (87,0%) Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының эшләүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүе өчен эш бирүчеләрдән тотып калына торган иминият акчаларыннан һәм Россия Федерациясе субъектының эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүе өчен иминият кертемнәреннән торучы субвенциясе белән тәэмин ителәчәк.

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан субвенцияләр түбәндәге күләмдә билгеләнде:

87 013,9 млн. сум – 2026 елга;

92 964,7 млн. сум – 2027 елга;

96 683,2 млн. сум – 2028 елга.

Субвенция күләме оешмалар хезмәткәрләренең исәпләп чыгарылган уртача айлык эш хакы арту темпын һәм агымдагы елда куллану бәяләренең фаразлана торган индексы күрсәткечен исәпкә ала.

Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар суммалары 2026 елга – 11 873,5 млн. сум, 2027 елга – 12 792,8 млн. сум һәм 2028 елга 13 782,2 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән:

мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәменә түләүгә – 2026 елга – 3 220,6 млн.сум, 2027 һәм 2028 елларга – тиешенчә 3 420,3 млн.сум һәм 3 631,9 млн.сум;

бер каналлы финанслау кысаларында медицина ярдәме күрсәтүгә – 2026 елда – 7 763,6 млн.сум, 2027 һәм 2028 елларга – тиешенчә 8 417,3 млн. сум һәм 9 127,4 млн. сум;

санитария авиациясенә, иминләштерелмәгән халыкка ашыгыч медицина ярдәменә – 2026 елда – 11,2 млн.сум, 2027 елда – 11,2 млн. сум һәм 2028 елда – 11,2 млн. сум;

паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән балаларга – 2026 елда - 700,6 млн. сум, 2027 һәм 2028 елларга – тиешенчә 759,5 млн. сум һәм 821,3 млн. сум;

гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары ясау хезмәтләре күрсәтүгә – 2026 елда – 177,5 млн. сум, 2027 елга – 184,5 млн. сум һәм 2028 елга – 190,4 млн.сум.

Россия Федерациясе субъектларының территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан бюджетара трансфертлар түбәндәге күләмдә планлаштырыла:

1 185,7 млн.сум – 2026 елга;

1 265,1 млн.сум – 2027 елга;

1 349,9 млн.сум – 2028 елга.

Фонд бюджеты чыгымнары, хезмәт өчен түләү фонды һәм агымдагы чыгымнар арту индексларын исәпкә алып, 2026 елга 100 073,0 млн. сум күләмендә билгеләнә, ул 2027 һәм 2028 еллар план чорына тиешенчә 107 022,6 млн.сум һәм 111 815,3 млн. сум тәшкил итәчәк.

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыру кысаларында күрсәтелгән медицина хезмәтләренә түләүгә акчаны түбәндәгечә җибәрергә планлаштырыла:

2026 елда – 99 608,5 млн. сум;

2027 елда – 106 559,0 млн. сум;

2028 елда – 111 311,5 млн. сум.

Фондның программага кертелмәгән чыгымнары түбәндәге күләмдә күздә тотыла:

464,5 млн. сум – 2026 елда;

463,6 млн. сум – 2027 елда;

503,8 млн. сум – 2028 елда.

Закон проекты белән иминләштерүче медицина оешмалары эшен алып баруга чыгымнар нормативы мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итүнең

җан башына дифференциацияләп исәпләнгән нормативлары буенча иминләштерүче медицина оешмаларына кергән акчалар суммасыннан 0,85 процент күләмендә карала.

Мәҗбүри медицина иминияте системасының тотрыклылыгын тәэмин итү өчен Фонд бюджетында Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары күләме 2026 елга – 5 745,1 млн. сум, 2027 елга – 6 135,5 млн.сум, 2028 елга 6 470,2 млн.сум күләмендә билгеләнде. Бу акчалар түбәндәге максатларга җибәреләчәк:

медицина ярдәменә түләү өчен җитешми торган акчаны иминләштерүче медицина оешмасына бирү юлы белән мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыруны өстәмә финанс белән тәэмин итүгә;

иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәме өчен мәҗбүри медицина иминиятенең база программасында каралган күләмдә исәп-хисап ясауга;

квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә;

гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яисә) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу янаганда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы белән билгеләнгән медицина ярдәме күләмнәре киметелүгә бәйле рәвештә медицина оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрен компенсацияләү чараларын финанс белән тәэмин итүгә.

2026 елда, 2027 һәм 2028 еллар план чорында Фонд бюджеты балансланa һәм кытлыксыз планлаштырыла.

**«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты белән Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба – Фонд) бюджетының керемнәр өлешен 2026 елга – 100 073,0 млн.сум, 2027 һәм 2028 еллар план чорына тиешенчә 107 022,6 млн.сум һәм 111 815,3 млн. сум күләмендә расларга тәкъдим ителә.

Фонд бюджетының керемнәр өлеше чыганаклары булып Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба – Федераль фонд) субвенцияләре, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Россия Федерациясе субъектларының территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан бюджетара трансфертлар тора.

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Федераль фонд бюджетыннан субвенцияләр күләме түбәндәгеләрдән чыгып хисаплап чыгарылды:

субъектта 2025 елның 1 гыйнвары хәленә карата мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән 3 827 613 кеше санынннан («Мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән затлар саны турында мәгълүматлар» дигән 8 нче форма мәгълүматлары буенча);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасы турында» карары белән территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын финанс белән тәэмин итүнең 2026 елга – 22 733,2 сум, 2027 елга – 24 287,9 сум күләмендә билгеләнгән һәм 2028 елга куллану бәяләре арту индексын исәпкә алып билгеләнә торган 25 259,4 сум күләмендәге нормативыннан.

Субвенция түбәндәге күләмдә фаразлана:

2026 елга – 87 013,9 млн. сум;

2027 елга – 92 964,7 млн. сум;

2028 елга – 96 683,2 млн.сум.

Фонд бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар күләме «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты белән каралган күләмнәргә туры килә, шул исәптән түбәндәгеләрне гамәлгә ашыруга:

медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны (мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәменә түләүне

кертеп) – 2026 елга, 2027 һәм 2028 елларга тиешенчә 11 696,0 млн. сум, 12 608,2 млн. сум һәм 13 591,8 млн. сум;

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары ясау хезмәтләре күрсәтү буенча адреслы социаль ярдәм чараларын – 2026 елга, 2027 һәм 2028 елларга тиешенчә 177,5 млн.сум, 184,5 млн.сум, 190,4 млн.сум.

Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан бюджетара трансфертлар, 2023 – 2025 елларда акча керү динамикасын һәм 2026 – 2028 елларга индекс-дефляторларны исәпкә алып, түбәндәге күләмдә планлаштырыла:

1 185,7 млн. сум – 2026 елга;

1 265,1 млн. сум – 2027 елга;

1 349,9 млн. сум – 2028 елга.

Закон проекты белән Фонд бюджетының чыгымнар өлешен түбәндәге суммада расларга тәкъдим ителә:

100 073,0 млн. сум – 2026 елга;

107 022,6 млн. сум – 2027 елга;

111 815,3 млн. сум – 2028 елга.

Чыгымнар 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Россия Федерациясен һәм Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп макроикътисадый параметрлары нигезендә хисаплап чыгарылды.

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджетның чыгымнар өлеше федераль (региональ) проектлар һәм процесс чаралары комплекслары буенча бүленде.

Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация эшләре сатып алуны тәэмин итүгә чыгымнар «Кичектергесез медицина ярдәмен камилләштерү» федераль проектында һәм процесс чаралары комплексында барлыгы түбәндәге күләмдә күздә тотыла:

2026 елга – 11,2 млн. сум;

2027 елга – 11,2 млн. сум;

2028 елга – 11,2 млн. сум.

«Югары технологияле медицина ярдәме һәм профилактика, диагностика, дәвалау һәм реабилитация ысулларын клиник апробацияләү кысаларында күрсәтелә торган медицина ярдәме» процесс чаралары комплексы түбәндәге күләмдә планлаштырыла:

2026 елга – 3 220,6 млн. сум;

2027 елга – 3 420,3 млн. сум;

2028 елга – 3 631,9 млн. сум.

«Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү» процесс чаралары комплексы түбәндәге күләмдә карала:

2026 елга – 700,6 млн. сум;

2027 елга – 759,5 млн. сум;

2028 елга – 821,3 млн. сум.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау

өлкәсендәге башка чаралар» процесс чаралары комплексы түбәндәгечә күздә тотыла:

2026 елга – 95 498,7 млн. сум;

2027 елга – 102 183,5 млн. сум;

2028 елга – 106 656,7 млн. сум,

шул исәптән:

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга – тиешенчә 7 763,6 млн. сум, 8 417,3 млн. сум һәм 9 127,4 млн. сум;

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә – тиешенчә 86 549,4 млн. сум, 92 501,1 млн. сум һәм 96 179,4 млн. сум;

Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафынан күрсәтелгән медицина ярдәменә – тиешенчә 1 185,7 млн.сум, 1 265,1 млн.сум һәм 1 349,9 млн.сум.

Гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары ясау хезмәтләре күрсәтү буенча социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру өлешендә «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү» процесс чаралары комплексы кысаларында түбәндәге күләмдә акча карала:

2026 елга – 177,5 млн. сум;

2027 елга – 184,5 млн. сум;

2028 елга – 190,4 млн. сум.

Дәүләт программалары белән каралмаган чыгымнар бюджетның программага кертелмәгән чыгымнары өлешен тәшкил итә, ул түбәндәге күләмдә күздә тотыла.

2026 елга – 464,5 млн. сум;

2027 елга – 463,6 млн. сум;

2028 елга – 503,8 млн. сум.

2026 елда, 2027 һәм 2028 еллар план чорында Фонд бюджеты баланслана һәм кытлыксыз планлаштырыла.

**«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, гамәлләре туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә яңалары кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокук актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының кайсы да булса законының һәм башка норматив хокук актларының үз көчен югалтуын тану, гамәлләрен туктатып тору, аларга үзгәрешләр кертү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.